| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.10.2019 г.Казань № 853

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 12 октяберендә 5852 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 06 апрелендәге 254 номерлы боерыгы белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2018 елның 09 февралендәге 67 номерлы карары белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 22 августындагы 698 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары чыгарылуга бәйле рәвештә боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 254 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 25 июлендәге 703 номерлы, 2018 елның 18

сентябрендәге 885 номерлы, 2019 елның 24 июнендәге 494 номерлы боерыклар нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 17.10.2019 г. 853 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 06 апрелендәге 254 номерлы боерыгы белән расланган Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – Россия Федерациясе гражданнары, түбәндәгеләр исәбеннән:

Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими, беренче бала туганда, мөрәҗәгать итү датасына кимендә өч ел яшәүче, 25 яшькә кадәрге хатын-кызлар;

Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими, өченче бала туганда, мөрәҗәгать итү датасына кимендә өч ел яшәүче, 29 яшькә кадәрге хатын-кызлар;

әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр вафат булган очракта яки ата-аналык хокукларыннан мәхрүм ителгәндә (ата-аналык хокукларында чикләнгәндә), әтиләре (опекуннар).»;

1.3 пунктны үз көчен югалткан дип таныргa;

1.4 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «мөрәҗәгать итүче» сүзенә алмаштырырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы булган органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентка белешмәлек кушымтада китерелде.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчаның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пуктның бишенче абзацында «(алга таба – РФ Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләрен «(алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктта:

икенче абзацта «арифметик хата» сүзләреннән соң «йә шуңа охшаш хата» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрҗәгать аңлашыла (210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 1 п.)»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына булган таләпнең атамасы | Стандартка булган таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең атамасы | Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләүне (алга таба – бер бирелә торган түләү) билгеләү | Нигезләмәнең 1 п. |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органының (учреждениенең) исеме | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | Нигезләмәнең 6 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | Бер бирелә торган түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар | Нигезләмәнең 8 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | Бер бирелә торган түләүне билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар бер бирелә торган түләүне билгеләү турында гариза кирәкле барлык документлары белән теркәлгән көннән башлап ун эш көне эчендә кабул ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган<br>Карарны бирү бер бирелә торган түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар кабул ителгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. | Нигезләмәнең 8 п. |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче | 1. Банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган хосусый счет реквизитларын күрсәтеп, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы форма буенча бер бирелә торган түләүне билгеләү турында гариза;<br>2. Бала (балалар) туу турында таныклык күчермәсе – бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән очракларда;<br>3) Ананың (атаның) вафат булуы турында таныклык күчермәсе – вафат булу акты Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән очракларда;<br>4. Гариза белән мөрәҗәгать итү көненә Татарстан Республикасы территориясендә авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда яшәү урыны буенча теркәлү вакыты өч елдан азрак | Нигезләмәнең 6 п. |

| | | |
|---|---|---|
| тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | булган очракта, – Татарстан Республикасы территориясендәге авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда кимендә өч ел даими яшәү фактын билгеләү турында законлы көченә кергән суд карары күчермәсе;<br>5. Вәкаләтле затлар өчен ышаныч кәгазенең күчермәсе.<br>Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация | |

| | | |
|---|---|---|
| | челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документлар 63-ФЗ номерлы Федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче аларны тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук, шул исәптән электрон рәвештә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>баланың (балаларның) тууы Татарстан Республикасы территориясендә дәүләт теркәвенә алынган очракта – бала (балалар) туунын дәүләт теркәвенә алу турындагы белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>ананың (атаның) вафат булуын дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр – вафат булу турындагы акт Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракларда (вәкаләтле органнарда);<br>опека (попечительлек) билгеләнүе турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);<br>ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителү турында яисә ата-аналык хокукында чикләнү турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарыннан);<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, Татарстан Республикасы территориясендәге авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими, кимендә өч ел яшәү фактын раслый торган белешмәләр<br>(җирле үзидарә органнарында);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият | Нигезләмәнең 7 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша | |

| | | |
|---|---|---|
| | торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы.<br>4. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында документларның төп нөсхәләренең күрсәтелмәве.<br>5. Үзәк бүлегенә электрон документлар формасында электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) гаризаның һәм документларның (документларның күчермәләренең) тапшырылуы.<br>6. Мөрәҗәгать итүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган | 210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>63-ФЗ номерлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | кучермәләрен почта аша җибәрүе. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Булган белешмәләр һәм документлар җыелмасы нигезендә дәүләт хезмәте алуга хокук булмавы ачыклану аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора | Нигезләмәнең 9 п. |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указының 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә. | |

| | | |
|---|---|---|
| исемлеге урнаштырылган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр. Шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә дә | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, | Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең һәркем өчен мөмкинлекле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында | Тәртипнең 2.4 п.; Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указының 1 п. |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләрен-нән файдаланып, мәгълүматны алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтен алу турында 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтен алу (шул исәптән тулы күләмдә) яки ала алмау мөмкинлеге; | дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>гаризаны электрон рәвештә тапшыру мөмкинлеге;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәләрен мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләренең әлеге Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлеге хезмәткәрләре белән бәйләнешкә керү саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – юк (консультацияләрне исәпкә алмыйча).<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең Үзәк бүлеге хезмәткәрләре белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү, дәүләт | |

| | | |
|---|---|---|
| | хезмәте күрсәтүгә гариза тапшыруны да кертеп, күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарында гамәлгә ашырылмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләре порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплексны мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы Федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.<br>Документларны (документларның күчермәләрен) электрон документлар формасында тапшырган очракта, әгәр алар 63-ФЗ номерлы Федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ һәм $21^2$ статьялары таләпләре нигезендә һәм (яки) | Нигезләмәнең 10, 11 п.; 63-ФЗ номерлы Федераль законның 2 ст. 11 п.; 210-ФЗ номерлы Федераль законның $21^1$ ст.;» |

| | | |
|---|---|---|
| | законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) булса, бер бирелә торган түләүне билгеләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларның төп нөсхәләре яки законнарда билгеләнгән тәртиптә кәгазьдә таныкланган күчермәләре Үзәк бүлегенә тапшырылганнан соң гамәлгә ашырыла. | |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

бер бирелә торган түләү билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әзерләү;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә мөрәҗәгать итүчегә тапшыру яки дәүләт хезмәте нәтиҗәсен почта буенча җибәрү.»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктның беренче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.4.1 пунктчаның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 2.5 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, Татарстан Республикасы территориясендәге авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими, кимендә өч ел яшәү фактын раслый торган белешмәләр, җирле үзидарә органнарыннан.»;

3.4.2 пунктчаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 2.5 пунктының дүртенче абзацында күрсәтелгән очрактан тыш, Татарстан Республикасы территориясендәге авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими, кимендә өч ел яшәү фактын раслый торган белешмәләр, җирле үзидарә органнарыннан.»;

3.5.1 пунктның икенче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хатаны төзәтү

«Техник хатаны төзәтү мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.2 пунктның беренче абзацында «(алга таба - Идарә (бүлек))» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәкнең хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлектә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлегенә

___________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № _____

_________ 20__ ел.

Мин,_____________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
(соңгысы – булган очракта)

түбәндәге адрес буенча яшим:

_______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

| Шәхесне таныклый торган документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:

_______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрендә эш итүче затның вәкаләтләрен
раслый торган документның реквизитлары, ышанычлы зат яки
законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счетының шәхси номеры_______________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү турында» 2018 елның 9 февралендәге 67 номерлы карары нигезендә

_______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)
түбәндәге адрес буенча яши:

_______________________________________________________________
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

_______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

__________ бала туганда бер бирелә торган түләүне билгеләвегез турында үтенәм.
(беренче (өченче))

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |
| 5 | | |

Мөрәҗәгать итүченең гаилә составы:

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (туган көне, ае, | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | елы) | | |
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |

Гаризада күрсәтелгән балаларның (баланың) тулысынча дәүләт тәэминатында тормавы хакында раслыйм, шулай ук аларга (аңа)

______________________________________________________________карата

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ата-ана хокукыннан мәхрүм ителмәгәнмен, ата-ана хокукларында чикләнмәгәнмен

__________ ______________________________

(мөрәҗәгать итүченең имзасы, тулы имзасы)

_________________________________________________________________

(балага опека билгеләнгәндә опека билгеләгән органның исемен һәм урнашу урынын күрсәтергә)

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:

__________________________________________ **счетына күчерү юлы белән**

(мөрәҗәгать итүче йә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, аларны үз эченә алган документларның төп нөсхәләре өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым ________________________________

Мәгълүмат алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза:

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп ______________________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

әлеге электрон почта адресы буенча ______________________________

(электрон почта адресы)

Мөрәҗәгать итүче:

________________________________________ ______«__» ________20__ ел.

(Мөрәҗәгать итүченең яисә билгеләнгән тәртиптә) (имза)

таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә

мөрәҗәгать итүченең мәнфәгатьләрен белдерүче

затның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гариза һәм документлар кабул ителде _______ 20__ ел. _____________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

______________________________________________________________________

Өзү линиясе

Язу-хәбәр

Мөрәҗәгать итүченең теркәлү №____________

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте __________ _________ ________________ _________

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)»;

Регламентка 2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Авыл җирлегендә, шәһәр тибындагы поселокларда даими яшәүче хатын-кызларга бала туганда бер бирелә торган түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы булган органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru» |